СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА
МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

25 декабрь, 2025 ел Алабуга шәһәре № 32

Алабуга муниципаль районы Советының «Алабуга муниципаль районында җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазифаи затларына, контроль-хисап палатасы рәисенә, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмә хакында» 2018 елның 25 апрелендәге 245 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазифаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 25 ноябрендәге 994 номерлы карары нигезендә, Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Алабуга муниципаль районы Советының 2018 елның 25 апрелендәге 245 номерлы карары белән расланган Алабуга муниципаль районында җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларына, сайланулы вазифаи затларына, контроль-хисап палатасы рәисенә, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертелергә:

1.1. Нигезләмәнең 3.1. пунктындагы 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәткәрләрнең вазифаи окладлары күләме авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең кече вазифалар төркеме белгеченең вазифаи оклады күләменә тапкырлар исәпләнә, ул 16 928 сум тәшкил итә.».

1.2. Нигезләмәнең 1 нче кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Нигезләмәгә 1 нче кушымта

Алабуга муниципаль районы башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, Алабуга муниципаль районындагы контроль-хисап органы рәисенең, рәис урынбасарының акчалата түләү күләмнәре

| Вазифалар атамасы | Айлык акчалата түләү, сумнарда |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Муниципаль берәмлек Башлыгы | 47 056 |
| Муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары | 42 348 |
| Депутат | 22 807 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары | 19 384 |
| Контроль-хисап органы рәисе | 42 348 |
| Контроль-хисап органы рәисе урынбасары | 38 086» |

2. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга тиеш һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны икътисади үсеш, бюджет, салымнар, тариф сәясәте, эшкуарлыкка ярдәм итү мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис урынбасары А.В. Косов